Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чистай авыл җирлеге Советы

Карары

2026 елның 16 феврале № 6/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
Районы Чистай авыл җирлеге Советының
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы «Чистай авыл җирлеге» муниципаль
берәмлегендә бюджет процессы турында
Нигезләмәне раслау хакында»10.02.2023 елның
№32/1 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.11.2025 ел, №432-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында «10.02.2023 ел, № 32/1 Чистай шәһәр Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.1 маддәсенең 7 пунктында «(муниципаль берәмлек)» сүзләреннән соң «, әгәр күрсәтелгән акчалар федераль казначылык органнары тарафыннан ачыкланмаган керемнәргә керсә һәм тиешле казначылык счетларында исәпкә алынса, бу очрактан тыш,» сүзләрен өстәргә.»;

1.2. 5.1 маддәсенең 13 пунктында «федераль законнар» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе субъекты законнары, җирле үзидарә вәкиллекле органының муниципаль хокукый актлары» сүзләрен өстәргә.;

1.3. 5.1 маддәсенең 11 пунктындагы 1 пунктчасының бишенче абзацында «контрактлар (шартнамәләр)» сүзләреннән соң «товарлар кайтару, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында» сүзләрен өстәргә.;

1.4. 5.1 маддәсенең 11 пунктының 4 пунктчасында «коммерциягә карамаган оешмаларга» сүзләреннән соң «(шартларында казначылык озатуы турындагы нигезләмәләр булган дәүләт контрактлары, шартнамәләр (килешүләр), контрактлар (шартнамәләр) нигезендә бирелә торган акчалардан тыш)» сүзләрен өстәргә.;

1.5. 5 маддәсенең 12 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 маддәсе нигезендә билгеләнә торган тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;».

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга) һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы Р. М. Мәгъсүмов